

БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ · ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ · CHILDREN'S MAGAZINE
№1. 2016
Салават күпере
0+


«SK» КАЛЕНДАРЬ


ГЫЙНВАР

ДҮШӘМБЕ	СИШӘМБЕ	ЧӘРШӘМБЕ	ПӘНҖЕШӘМБЕ	ҖОМГА	ШИМБӘ	ЯКШӘМБЕ
				1 ЯҢА ЕЛ!	2 Беренче тапкыр айга очу көне	3 Тимераякта шуу көне
4 Бөтендөнья үбүләр көне	5 Базар икътисады көне	6 Хыялланучылар көне	7 Раштуа бәйрәме	8 Балалар киносы көне	9 Саф һава сулау көне	10 Имбирлы прәннекнең туган көне
11 Бөтендөнья «Рәхмәт» көне	12 Могҗиза көне	13 Россия матбугаты көне	14 Иске Яңа ел	15 Википедиянең туган көне	16 Җырлау көне	17 Балаларның кул эшләнмәләре көне
18 Аулак өй көне	19 Бөтендөнья кар көне	20 Мәзәкләр көне	21 Кочаклашу көне	22 «Салават күпере»нә хат язу көне	23 Төсле карандашлар көне	24 «Эскимо»ның туган көне
25 Студентлар көне	26 Бөтендөнья таможнячы көне	27 Электр лампочкасы туган көн	28 Йорт иясе көне	29 Автомобиль уйлап табуга 130 ел	30 Кыш бабай һәм Кар кызы көне	@31 Халыкара интернетсыз көн


VKontakte он-лайн тавыш бирүдә җиңүчеләр!
Бәйге дәвам итә!

МИН «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»Н УКЫЙМ!


Самат, 3 яшь, Тәтеш.


Айгиз, 2 яшь, Актаныш.


Раниль, 3 яшь, Эмиль, 5 яшь, Казан.


Камил, 12 яшь, Әдилә, 8 яшь, Рамил, 2 яшь, Актаныш.


Әминә, 7 яшь, Казан.


Камилә, 8 яшь, Казан.

© «Салават күпере», 2016 ел.

ҖИҢҮЧЕГӘ – ПЛАНШЕТ!

ҖЫЙ ҺӘМ ҖИҢ 2!

Яңа елда да безнең белән булганыгыз өчен рәхмәт! Нәкъ менә шундый дусларыбызга атап яңа бәйге игълан итәбез!

Түбәндәге рәсемдә төрле күләгәләр бирелгән. Сиңа ел буе туры килгән рәсемнәрне журналдан табарга, кисәргә һәм тиешле урынга ябыштырып куярга кирәк (һәр санда бер рәсем булачак). Килеп чыккан апликацияне 2016 елның 20 декабренә кадәр квитанция күчермәсе белән salavatkupere@mail.ru яки Декабристлар урамы, 2 йорт адресына «ҖЫЙ ҺӘМ ҖИҢ 2» тамгасы белән кабул итәбез. Җиңүче җирәбә буенча билгеләнәчәк. Барлык катнашучыларны дипломнар көтә. Җыя башлыйбызмы?





ТИМЕР АТЛАР



Бүгенге көнебезне, яшәвебезне машиналарсыз күз алдына китереп булмый. Алар күбебезнең яраткан уенчыгы булып тора. Ә үсә төшкәч, без әти-әниләребез кебек рульгә утырып, илләр-юллар гизәргә хыялланабыз. Ә кайдан килеп чыккан соң ул автомобиль?



Кешеләр башта атларда гына йөргән. Тора-бара аңа тәгәрмәчле арба уйлап тапканнар. Ләкин кешеләрнең аттан да тизрәк йөри торган чара уйлап табасылары килгән.

Шуңа 1769 елда Англиядә һәм Франциядә пар белән эшли торган машина уйлап чыгарылган. Ләкин мондый автомобиль 10-15 минут кына бара алган. Ә 1886 елда немец инженеры Карл Бенц двигатель белән эшләүче өч тәгәрмәчле автомобиль уйлап тапкан. Бу тарихи вакыйгага инде 130 ел булган!



Чит илләрдә Шевроле, Кадиллак, Ситроен, Ягуар, Порш, Фиат, Рандж Ровер, Рено машиналары эшләнелә. Аларның күбесе камилләштерелеп бүгенге көндә дә чыгарылып килә. Бу рәткә заманча Тойота, Мерседес-Бенц, БМВ, Хонда, Форд, Фольксваген автомобильләре өстәлә.

Алга таба транспорт чаралары камилләшә, яңа төрләре барлыкка килгән. Алар арасында җиңел машина, йөк машинасы, автобус, троллейбус, кар чистартучы машина, ашыгыч ярдәм машинасы һәм башкалар бар.



Россиядә беренче автомобиль 1896 елда Евгений Яковлев һәм Петр Фрезе тарафыннан төзелә. Бөек Ватан сугышыннан соң Москвич, Победа, Волга, Запорожец, Жигули кебек җиңел машиналар киң тарала.





Автомобильнең тагын нинди төрләрен беләсең?
Трактор һәм мотоцикл автомобиль булып саналамы?
Россиядә беренче автомобиль төзелүгә ничә ел булган?
Зур үскәч нинди машина йөртергә хыялланасың? Ни өчен?



Дөньяда иң озын автомобиль – 30,5 метрлы лимузин. Аның ике йөртүче кабинасы, 26 тәгәрмәче, ике моторы бар.

Иң кечкенә Пил исемле машина 1962 елда Бөек Британиядә чыгарыла. Аның озынлыгы 134, ә киңлеге 99 сантиметр була. Аның эченә йөртүче генә сыя.





Күп кенә машиналарга аны уйлап табучылар исеме бирелгән.

Иң зур автомобиль – ул Германиядә эшләнгән үзбушаткыч. Аның авырлыгы – 200 тоннадан артык. Мондый машина белән бер зур өйне күтәрергә булыр иде!

Дустым, әлеге шакмакларда төрле транспорт чаралары исемнәре яшерелгән. Шуларны тап.


К	А	М	А	В
Ш	К	А	Т	Т
Н	О	З	А	О
И	Д	А	К	Б
В	А	И	С	У
К	Р	А	Н	С


Җаваплар salavatkupere.com сайтында.

Рәсемнәрдә нәрсәләр ясалган?
Кыш фасылына туры килгәннәрен тамга белән билгелә.





















Рәсемнәр арасында 8 аерма тап.
Рәссам нинди хата ясаган?





Табышмакларның җавабын тап. Әлеге табигать күренешләре турында кечкенә хикәя төзеп сөйлә.

Утта янмый,
Суда батмый.
(Боз)

Аягы юк, кулы юк,
Тәрәзәгә гөл ясый.
(Суык)

Канатсыз оча,
Аяксыз чаба.
Тышта өелә,
Өйдә җәелә.
(Кар)

Үзе ямьсез ыжгыра,
Кар буранын туздыра.
(Буран)



Рәсемнәр урынына сүзләр куеп, хикәяне укып чык.

АП-АК ТУНЛЫ КУЯНКАЙ

Кыш.  **ява. Барлык**  **суыктан куркып, өннәренә качкан. Ә нәни өне дә, да юк. Бер көн ул берәр астында йоклый, башка вакытта кар өемен казып ясый да, шунда кереп поса. Куянның**  **җылы, йомшак һәм ап-ак. Бу матур**  **бер дә туңмый, аңа дошманнардан качарга ярдәм итә. Ап-ак**  **ята да, аны**  **дә, дә күрми кала. Менә нинди хәйләкәр !**



Диләрә ШӘМСЕТДИНОВА,
Казан, 8 нче балалар
бакчасы, 6 яшь.



Алмаз ХАРИСОВ,
Сарман, Азалак мәктәбе,
3 нче сыйныф.



Лилия ХӘБИРОВА, Баулы,
Татар Кандызы мәктәбе,
3 нче сыйныф.



Гүзәл ГАЗИЗОВА,
Актаныш, Пучы мәктәбе,
2 нче сыйныф.



Айгөл БИКМОРАТОВА,
Казан, 13 яшь.




Ислам БӘДРИЕВ, Теләче,
Иске Җөри мәктәбе,
3 нче сыйныф.



Нәргизә ЗАЛАКОВА,
Казан, 8 нче
балалар бакчасы, 3 яшь.



Зилә ЛОКМАНОВА,
Арча, Шекә балалар
бакчасы, 6 яшь.



Ринат ГЫЙЛӘҖЕВ,
Сарман, Азалак мәктәбе,
3 нче сыйныф.

СИНЕҢ РӘСЕМНӘРЕҢНЕ ДӘ КӨТЕП КАЛАБЫЗ!

Кадерле дуслар!

Журналның урта битен иплəп кенə алып, кара сызыклар буенча кисегез, сары сызыклар буенча бөклəгез дə, килеп чыккан кисəкчеклəрне, бит саннарына карап, китап итеп җыегыз. Уртасын ике урыннан төплəп тə куйсагыз, нəни китапчык килеп чыгачак.

«Салават күпере» китапханəсе
2016

Сəлəвəт күпере

Рəссам Əлфия Йосыпова

Зиннур Мансуров

ТУГАН ҖИР РƏСЕМЕ
КАРТИНА РОДНОГО КРАЯ
PICTURE OF MOTHERLAND




КАР ТОТУ

Эштəн кайткач, əйтə əти:
«Ай-яй, улым, арыта!
Арытмыйча, кичкə кадəр
Игенлектə кар тот та...»

Энекəшем интектерə:
«Тоткан кары кайда соң?»
«Басуда ул – аны өйгə
Ничек алып кайтасың?!»

Кар тотуны җəнлек аулау
Итеп күрə, мөгаен.
Алдамыйча аңлатуның
Ничек табыйм соң җаен?!





Зиннур Мансуров
Зиннур Мансуров
Zinnur Mansurov

SNOW CATCH

My dad came home all exhausted
«My dear son, I'm very tired!
To help the grains be abundant,
We captured the snow in the field.»
My younger brother
wouldn't stop asking:
«Where's the snow
that father has caught?»
«The snow is in the field,
covering the rye,
There's no way
it could have been brought.»
My brother's little,
he doesn't understand
That snow catching isn't hunting,
How to tell him without lying,
How to explain the details of that?

КАРТИНА РОДНОГО КРАЯ

В родном краю
Так много
И пастбищ, и лугов,
Речных долин и пашен,
И на гумне стогов...

А снег-то, снег каков!
До крыш растут сугробы –
И ветер на току
Кружит, не уставая
Снег сеет, как муку.

А снег-то, снег каков!
Невидимый художник
На полотно снегов
Наносит штрих последний –
И снегири садятся
На шапочки стогов.

Перевод Талии Шарафиевой.

SPIDER'S ENTERPRISE

The spider started up
a remarkable business,
Day in day out he's knitting warm socks.
At first all the socks were knitted in pairs,
All forest residents kept warm
in the frost.
The hare and the fox used to walk
around freezing,
Now knitted accessories look nice
on their paws.
Animals wrote from all over of the forest,
The hundred-legged bug placed
a special order:
She needed warm socks to survive
in cold water
And requested footwear for all hundred
legs.
Knitting dozens of socks day in and
day out,
The spider quickly became famous and rich.
He gave up weaving his dangerous
cobweb –
No more hunting, he has socks to stitch.

СНЕГОЗАДЕРЖАНИЕ

Придя домой отец сказал:
«Ай-яй, сынок, как я устал!
Чтоб славным нынче вырос хлеб,
Задерживали в поле снег».

Вот младший брат
ко мне пристал:
«Где снег, что папа задержал?»
«Снег в поле, укрывает рожь,
Его домой не принесешь».

Братишка мал, не смог понять
То, что отец хотел сказать:
Валами трактор снег сгребал –
Чтоб долго в поле он лежал.

Как объяснить, как рассказать,
Чтоб ненароком не соврать?!

Зиннур Мансуров 1949 елның 15 июлендә Татарстанның Мамадыш районы Түбән Ушмы авылында туа. Югары белемне Казан дәүләт университетында ала. «Ватаным Татарстан» газетасында, «Казан утлары» журналында, Татарстан радиосында сәнгать тапшырулары программаларының баш мөхәррире һәм берничә ел Язучылар берлеге рәисенең урынбасары булып эшли. Бик күп еллар «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррир вазыйфасын башкара.

Зиннур абый Мансуровның беренче шигырьләре «Иркен минем туган илем» исемле җыентыкта басыла. Балаларга атап язган шигъри китаплары – «Алып батырга шелтә», «Кайда нәрсә пешә?».

Шагыйрь 2009 елда ТР Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

СМЫШЛЁНЫЙ ПАУЧОК

Хорошую фирму смышленый
открыл паучок:
Купил себе пряжу и спицы,
вязальный крючок.
Носочки он вяжет и парами их продает.
Смотрите, в обновках
лесной щеголяет народ.
Дрожали от холода раньше
зайчишка с лисой,
А в теплых носках
им не холодно будет зимой.
И каждой зверюшке носочки связал паучок.
А как-то однажды... ему написал Осьминог:
– Большою семьёю отправились
нынче в поход,
И дней через десять достигнем
арктических вод.
Поэтому вас, паучок, убедительно просим
Нам выслать носков шерстяных
в каждой связке по восемь.
Без отдыха мастер
над этим заказом корпел –
Управился в срок он и сразу же разбогател.
С тех пор паутины свои по углам не плетет,
Теперь с комарами и мухами
в дружбе живет.

PICTURE OF MOTHERLAND

Our motherland is full,
Abundant of beauty:
River valleys,
Stacks of hays,
Grazing lands and meadows.

And the snow, oh the snow!
Snow banks grow to roofs,
Surrounding the buildings;
The wind at the barn-floor
Sifts the snow as flour.

And the snow, oh the snow!
Made an enormous canvas,
As if something was missing,
An artists added a point –
On the tops of haystacks
Bullfinches sat down.


Translation Dilyara SHARIFULLINA.

ТУГАН ҖИР РӘСЕМЕ

Елга үзәннәре,
Җәйләү утарлары,
Ындыр табаклары –
Мөлдерәшеп тулган
Туган җирдә бары.


Аһ, кары да кары!
Амбарларга үргән,
Келәтләргә кергән;
Теземнәрдә җилли,
Җил он итеп или...

Аһ, кары да кары,
Быел бигрәк уңган!
«Нидер җитми», – диеп,
Рәссам «нокта» куйган –
Кибән очларына
Кызылтүшләр кунган.



ҮРМӘКҮЧ ШИРКӘТЕ

Үтә яхшы ширкәт ачкан үрмәкүч,
Оекбашлар бәйли җырлап иртә-кич.
Әүвәл монда оек парлап сатылды,
Бу киемнән һәммә кеше шат булды.
Куян, Төлке йөри иде гел өшеп,
Оекбашлар тора шундый килешеп!
Хатлар килде
төрле-төрле җанвардан,
Хәтта берчак... Сигезаяк ялварган.
Бозлы суга күченәчәк ун көннән,
Сигез бәйләм җибәрүне үтенгән.
Кырыгышар оек бәйләп иртә-кич,
Бик тиз генә баеп киткән Үрмәкүч.
Чебен-черки аулавын ул ташлаган,
Пәрәвезен инде үрми башлаган.



АЯК КИЕМНӘРЕ ИЛЕНДӘ



Дустым, бүген «Аяк киеме ничек һәм кайчан барлыкка килгән? Аяк киеменең нинди төрләре була?» дигән сорауларга бергәләп җавап эзләрбез.



ЧИТЕКНЕ БИЗӘ





















Беренче аяк киемнәре моннан 30 мең ел элек барлыкка килгән. Борынгы Мисырда пальма агачы яфракларыннан сандал ясап кигәннәр, аякка аларны күн каешлар белән бәйләгәннәр. Борынгы Грециядә бәйләнә торган күн итекләр дә текkәннәр. Америка индеецлары аякларын гевея дигән үлән суына тыккан. Шул үлән суы аякта кипкән һәм резин аяк киемен хәтерләткән. Вакытлар үтү белән аяк киемнәренең төрләре һәм эшләнү материаллары үзгәргән, камилләшкән.

ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР

- **Аяк киеме аяк үлчәменә туры килергә һәм җайлы булырга тиеш.**
- **Ел фасылына һәм һава торышына карап аяк киемнәрен үзгәртеп торасы.**
- **Аяк киемен җылыткычта түгел, ә эченә гәҗит тутырып бүлмәдә киптерергә кирәк.**
- **Вакытында төзәтеп, юыпчистартып, кремлап тору мәҗбүри.**





Бары тик 18 нче гасыр ахырында гына аяк киемнәрен үлчәмнәр буенча тегә башлаганнар.

Аяк киеменең төрләре күп: итек, ботинка, туфли, сандал, мокасин, чүәк, тәпкәләр. Үз эчендә алар күп кенә төрләргә бүленә. Мәсәлән, хатын-кызлар, ир-атлар, балалар аяк киеме. Итекләрнең дә күн, резин, киездән эшләнгәннәре була. Шулай ук һәр халыкның үзенә генә хас милли аяк киемнәре дә бар.

Синең дә әкият, шигырь, хикәяңне журнал битендә күрәсең киләме? salavatkupere@mail.ru адресына язмаң белән исемең, яшең, кайдан икәнлегеңне күрсәтеп хат яз! Дуслар, язмаларның иң-иңнәре генә журналыбызда урын ала. Калган эшләр белән salavatkupere.com сайтында танышырга була.

КЫШ

Менә тагын кышлар җитте,
Тып-тын гына кар ява.
Урам буйлап кар көртләре
Зурая да зурая.
Кыш көннәрен яратам мин,
Тышта суык булса да.
Рәхәтләнеп чана шуам,
Бит-кулларым туңса да.

Эльмира ХИКМӘТУЛЛИНА,
Әгерҗе, Яңа Бәзәкә
башлангыч мәктәбе,
4 нче сыйныф.



КЫШКЫ МАТУРЛЫК

Нинди сихри матурлык –
Кар ява тышта.
Бу мизгелне күзәтәм
Ел саен кышта.
Күңелемә якын минем
Салкын көннәре.
Беркайчан да онытылмас
Айлы кичләре.
Аеручы ошый миңа
Агач бәсләре.
Алмаз кебек ялтырыйлар
Бозның өсләре.

Сөмбел САБИРҖАНОВА,
Әгерҗе, Кырынды,
4 нче сыйныф.

САША ПЯТЁРОЧКИН – ДВОЕЧНИК

Жил-был мальчик, его звали Саша Пятёрочкин. Он был учеником 3 класса и учился на двойки. После уроков он гулял на улице, смотрел телевизор, играл в приставку. Так бессмысленно он проводил свои дни.


Но однажды он пришел из школы и, как обычно, бросил свой рюкзак. Из рюкзака выпала большая, красная двойка и заговорила с ним:

– Молодец, Саша, продолжай так учиться! Я хочу, чтобы у меня было много друзей!

Саша этого очень испугался и, даже не пообедав, сел за уроки. Сделал уроки по всем предметам и подготовил рефераты. На следующий день Саша получил пятёрки. После этого случая Саша делает уроки каждый день. Теперь он не Саша Пятёрочкин-двоечник, а Саша Пятёрочкин-отличник.

Эльза БАРАНОВА, Набережные Челны, 58 школа, 4 класс.

КАР БӨРТЕГЕ РӘСЕМЕН ЯСАРГА ӨЙРӘН
ҺӘМ БЕЗНЕҢ VKONTAKTE БИТЕНӘ ҖИБӘР.





Шалай укырга, мәктәпкә йөрергә, дәрес әзерләргә яратмый. Ә менә дусларының кытай телен өйрәнә башлауларын ишеткәч, аның да бу телне өйрәнеп, белемле буласы килә башлады.

Ярый әле, ярдәмгә кытай теле белгече Нариман абый Димөхәммәтов килде һәм Шалайга кызыклы дәресләр бирде.

Әйдә, дускай, син дә кушыл!

Беренче дәрес:

ТАВЫШ ТОНЫ

Кытай телендә төп 4 тавыш, ягъни тон бар. Алар сүз өстендә 4 төрле таякчыклар белән билгеләнә.

1 [mā]



Тавыш тигез яңгырый.

2 [má]



Сүз ахырына тавыш югарырак күтәрелә.

3 [mǎ]



Тавыш башта югары була, аннары төшә, сүз ахырына кабат югары менә.

4 [mà]



Тавыш югарыдан түбән төшә.

КҮНЕГҮ

[bā] [bá] [bǎ] [bà]

[dā] [dá] [dǎ] [dà]

ОНЫТМА



Тавыш тоны дөрес булуы бик мөһим, чөнки сүзнең ничек әйтелүенә карап, мәгънәләре дә төрле була.

МИСАЛ

八 [bā] *сигез*

拔 [bá] *тартып чыгару*

靶 [bǎ] *мишень*

爸 [bà] *əmu*



Видеодәрес «Салават күпере»нең VKONTAKTE битендә.

БЕЗДӘ – БӘЙРӘМ!


Ләззәт Илдар улы Хәйдәров җиңүчеләрне котлый.


Римма Атлас кызы Ратникова Зиннур Хөснияргa ТР Президенты Р.Н. Миңнехановның Рәхмәт хатын тапшыра.


Кыш бабай «Китап сере» бәйгесенең иң яшь катнашучысы белән.

Ур-ра, ур-р-ра! 24 декабрь көнне Татарстанның Халыклар дуслыгы йортында «Салават күпере» журналының 25 яшьлек туган көненә багышланган бик матур бәйрәм булып узды! Чара Татарстан Республикасының Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Журналистлар берлеге рәисе Римма Атлас кызы Ратникованың котлау сүзләре һәм аның журнал редакциясенә ТР Президенты Рөстәм Миңнехановның Рәхмәт хатын тапшыруы белән башланып китте.

Балачак бәйрәменә балалар, «25 туган көн», «Багалмам», «Китап сере» бәйгеләренең җиңүчеләре чакырулы иде.

«25 туган көн» бәйгесенең 25 җиңүчесенә «Татмедиа» агентлыгы эшләр белән идарә итүчесе Ләззәт Хәйдәров «ТАТМЕДИА» җәмгыятеннән планшетлар бүләк итте һәм «Салават күпере» журналының истәлекле дипломнарын тапшырды.


«25 туган көн» бәйгесе җиңүчеләре.

Татарстан Язучылар берлеге белән үткәрелгән «Багалмам» бәйгесенең җиңүчеләре: «Иң яхшы хикәя» авторы – Энҗе Миргаяз кызы Разова («Сәйди басмасы» хикәясе, Актаныш), «Иң яхшы әкият» язучы – Зинфира Равис кызы



«Багалмам» бәйгесе җиңүчеләре ТР Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан белән.

Гарифуллина («Кар бөртеге малае» әкияте, Мөслим), «Иң яхшы шигырь» иҗат итүче — Алисә Альберт кызы Сабирҗановага (Казан) истәлекле бүләкләр тапшырылды.

«Китап сере» бәйгесе шартлары буенча журналыбызның яшь укучылары «Татарстан китап нәшрияты» китапларында яшерелгән сүзләрдән серле татар халык мәкален табарга тиеш иде.

Китапларда яшерелгән «Кояш җирне яктырта, уку — кешене» мәкален табып, редакция адресына дөрес җавап юллаучылар җиңүче дип табылды: Рәниф Хафизов (Мөслим, Яңа Сәет), Камилә Закирова (Балтач, Кариле), Ислам Бәдриев (Теләче, Иске Җөри), Альмир Мифтахов (Әлмәт, Кама-Исмәгыйль), Илдан Шәрифуллин (Яр Чаллы), Фәридә Шәрәфиева (Казан, 6 нчы гимназия), Әдилә Денмөхәммәтова (Казан), Камилә Гыйләҗиева (Казан), Кәрим Сәләхеев, Рәсим Сәләхеев (Мамадыш), Рифат Мөкътәсимов (Чирмешән, Иске Кади), Данис Әхмәтҗанов (Саба, Килдебәк), Ләйлә Мөхәммәтдинова (Кукмара), Алинә Мөҗипова (Балтач), Гомәр Камалиев (Балтач), Камилә Нургалиева (Тәтеш, Кече Әтрәч), Дәниф Хәйруллин (Яшел Үзән, Мамадыш Әнил), Кайбыч районы Кошман төп гомуми белем мәктәбенең 4 нче сыйныф укучылары, Әдилә һәм Әмирхан Хәнәфиевлар (Кукмара), Казан шәһәре Мәскәү районы 2 нче татар гимназиясенең 3 нче сыйныф укучылары. Алар «Салават күпере» журналының тәмле бүләкләренә һәм китапларга ия булды.



«Китап сере» бәйгесе җиңүчеләре.

Ә инде чараны Кыш бабай һәм Кар кызы алып баруы, «Арлекино» бию төркеменең, Энҗе Әхмәтҗанова, Айрат Нигъмәтуллин кебек кечкенә дусларыбызның чыгышлары бәйрәмебезгә тагын да ямь өстәде. Алдагы елларда да «Салават күпер»ле бәйрәмнәр күбрәк булсын иде!

Бәйрәм турында тулырак мәгълүматны salavatkupere.com сайтында укырга була.

Марс МАКАРОВ

КУРЫКМАС КУЯН



Борын-борын заманда яшәгән, ди, Кирам атлы бер аучы. Ул куяннар ауларга яраткан, ди. Хәзер сезгә Кирамның ничек итеп куян аулавы турында сөйлибез. Кирам спортчы булган. Җәен суда йөзгән, кышын чаңгыда йөргән. Ул бүреләр аулаган, төлкеләр тоткан, тик куянга гына бер тапкыр да мылтыгын төзәргә йөрәге җитмәгән. Һәм урмандагы берәр куянны атмыйча гына тотып, үз йортына алып кайтып тәрбияләргә хыялланган. Ләкин ничек итеп кыргый урман куянын терелэй кулга төшерергә?

Бик озак баш ватканнан соң аучы Кирам шундый хәйлә корган: күзгә күренми торган нечкә тимер чыбыктан капкын эшләп, куяннар эзенә шуны куйган һәм өенә кайтып киткән. Икенче көнне иртә таңда бер куян шул капкынга эләккән. Кирам куянны капчыкка салып өенә алып кайткан. Аны, кишер яфраклары белән сыйлап, кулга ияләштерергә керешкән.


Көннәр-төннәр үткән. Шулай итеп, куркак куян йорт куянына әйләнгән һәм бар да аны «Курыкмас куян» дип йөртә башлаганнар.

- **КИРАМ НИНДИ ҖӘНЛЕКЛӘР АУЛАГАН?**
- **УЛ НИНДИ ХӘЙЛӘ КОРА?**
- **КИРАМ КУЯННЫ НИЧЕК ТӘРБИЯЛӘГӘН?**

КЫРГЫЙ – ДИКИЙ – WILD [УАЙЛД]
КЫР – ПОЛЕВОЙ – FIELD [ФИИЛД]
КАПКЫН – ЛОВУШКА – TRAP [ТРЭП]

Әкияттәге курыкмас куянны киләсе биттәге үрнәк буенча үзең дә ясап кара.


SKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSKWORDSK







Бирелгән өлешләрне кисеп ал, ярымтүгәрәкне конус итеп бөклә һәм ябыштыр, әзер куян гәүдәсенә калган өлешләрен дә дөрес итеп беркет.



ӘЙ СИН БЕЛӘСЕҢМЕ?

• Куяннарны җир шарының барлык илләрендә дә очратырга мөмкин.

• Аларның тешләре гомер буе үсә.

• Куяннарның колаклары аларны җәйге эсседән дә, көзге яңгырдан да саклый.

• Әлеге җәнлек кәбестә, кишер һәм башка яшелчәләрдән кала ит белән дә туклана.





№1 (310) – 2016

Журнал 1990 елның март аеннан бирле чыга.
Журнал выходит с марта 1990 года.

Директор
Зиннур ХӨСНИЯР (ХӨСНЕТДИНОВ Зиннур Зыятдин улы)

Баш мөхәррир
Зилә ЯЗ (ХӨСНЕТДИНОВА Зилә Зиннур кызы)

Баш мөхәррир урынбасары
Гүзәл ЗИННӘТУЛЛИНА

Мөхәррирләр
Гөлназ ЯРМИЕВА
Алсу НИЗАМИЕВА

Баш рәссам
Әлфия ЙОСЫПОВА

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

0+ Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тесләргә бүленде.

Басарга кул куелды 12.01.16 ел.
Кәгазь форматы 60х90 1/8.
Гарнитура – Букварь.
Офсет ысулы белән басыла.
Заказ: М-14. Тираж: 9950 данә.

Килгән хатлар, кульязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми, авторларга кире кайтарылмый.

Почта гаебе белән журнал ийәсенә килеп җитмәсә, түбәндәге телефон белән газета-журналлар экспедициясенә шалтырата аласыз: (843) 562-10-66.



Журналны гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ.

Татарстан республикасы матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәмендә чыгарыла.

Бәясе ирекле. Индекс: 73953.

Тышлыкта рәссам Susan Wheeler рәсеме (Holly Pond Hill сериясе, art-dot.ru сайтыннан алынды).

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Казан, Академическая ур., 2 й.
Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 й., 10 кат.
Тел.: (843) 519-45-89.
E-mail: salavatkupere@mail.ru
Сайт: www.salavatkupere.com

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт тарафыннан ФС77-54277 номеры белән 2013 елның 24 маенда теркәлде.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 й.

Газета-журналга язылган өчен iPad!

1 Языл
30.12.2015 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

2 Җибәр
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 Җиң
Айпад, фотоаппарат һ.б. бүләкләр отарга ашык!



Акциянең спонсоры

KUKMARA «КУКМАРА МЕТАЛЛ САВЫТ-САБАЛАР ЗАВОДЫ»

Kukmara

Сделано в России







ISSN 0868-4545



Акцияне үткәрү вакыты: 01.11.2015 - 10.03.2016
Акция турында тулырак мәгълүмат - tatmedia.ru сайтында.
Оештыручы - «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 (өстәмә номер 1261).

16+
Реклама